Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Советы

# КАРАРЫ

2021 елның 3 марты 36№

2021 елгаТатарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 50 һәм 51 ст., 85 ст. 8 п. 4 п., 2001 елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендәге мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга

2. Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2021 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын гамәлгә ашырырга .

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми www.alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясенең рәсми www.torgi.gov.ru сайтында урнаштырырга.http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки муниципаль район башлыгы: А. Ф. Никошин

Татарстан Республикасы Әлки
муниципаль район Советының 2021 елның
3 мартындагы 36 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2021 елга Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы)**

## 1Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2021 елга Татарстан Республикасының «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба муниципаль мөлкәт) 2001 елның 21 декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы «Әлки муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. 2021 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 Бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2021 елда Әлки муниципаль районы бюджетыннан финансланучы муниципаль казнадагы һәм оешмалар файдаланмаган муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2. Хосусыйлаштырырга планлаштырылган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Мөлкәтнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдаланугa тапшыру елы, (чыккан елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Автотранспорт чарасы MERCEDES-BENZS 500 4M идентификация номеры (VIN) WDB2201841A469901 җиңел Теркәлү номеры: Р 321 КЕ 16 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2005 | 2,3 квартал |
| 2 | Hyundai Sonata автотранспорт чарасы VIN X7MEN41FP7A030360 җиңел Теркәлү номеры: Р 332 ХО 116 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2007 | 3,4 квартал |
| 3 | FORD "Фокус" автотранспорт чарасы VIN X9FMXXEEBMCT75684 җиңел Теркәлү номеры Р 346 ХО 116 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2012 | 2,3,4 квартал |
| 4 | Lada 211230 машинасы VIN XTA21123089006363 Теркәлү номеры: Р 498 ХО 116 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2008 | 2,3 квартал |
| 5 | Автотранспорт чарасы HYUNDAI Sonata VIN X7MEN41HP9M049196 җиңел Теркәү номеры У 229 АА 116 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2009 | 3,4 квартал |
| 6 | TAYOTA LAND CRUISER 200 VIN автотранспорт чарасы JTMHT05J105027464 җиңел Теркәлү номеры Р 226 КО 116 | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Базарлы Матак авылы | 2008 | 3,4 квартал |

## 3 Бүлек  Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү

3.1. Әлки муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре Палатасы муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан әлеге фараз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.